| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16.09. 2019 ел** **Мәлки авылы** **№16**

**Мәлки авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә Мәлки авыл җирлеге Советы КАРАР кабул итте:

1. Мәлки авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Мәлки авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2020 елда Мәлки авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:*

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- агачлар кистерү;
- материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;
- су башнясын төзекләндерү, яңарту һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:*

- зиратларны тезекләндерү һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә чистартып тоту өчен материаллар сатып алу.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http:// molkeev - kaybici.tatarstan.ru.
3. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Мәлки авыл җирлеге башлыгы** **Ф.П.Поляков**

Совет Молькеевского сельского поселения
Мәлки авыл җирлеге Советы